СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 192 от 09.01.2018
на № ________ от ____________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфасына конкурс үткәрү турында

В соответствии со статьей 37 Федерального закона от 06.10.2003 года №131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации», статьей 26 Закона Республики Татарстан «О местном самоуправлении в Республике Татарстан», статьями 46–48 Устава Сабинского муниципального района Совет Сабинского муниципального района РЕШИЛ: Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы, Саба муниципаль районы Уставының 46-48 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы, Саба районы, Байлар Сабасы бистәсе, Г.Закиров ур., 52 нче йорт адресы буенча урнашкан администрация бинасының актлар залында 2018 елның 31 гыйнварында 10.00 сәгатьтә Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрергә.
2. 2018 елның 10 гыйнварыннан алып 2018 елның 30 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы, Байлар Сабасы бистәсе, Г.Закиров урамы, 52 нче йорт адресы буенча, 315 нче кабинета, ял һәм бәйрәм көннәреннән тыш, көн саен документлар кабул итәргә, телефон 8(84362)2-34-44.
3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибен расларга (теркәлә).
4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе белән контракт шартларын расларга (теркәлә).
5. Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына конкурс үткәрү өчен 6 әгъза күләмендә конкурс комиссиясен төзергә.

6. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башкарма комитетлары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә кандидатураларны карау өчен Конкурс комиссияләре әгъзаларын билгеләү турында»гы 2014 елның 22 декабрендәге ПУ-1164 номерлы Указын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатураларны карау өчен Конкурс комиссиясе әгъзаларын билгеләп куярга:

Сафиуллин Марат Әдип улы - комиссия рәисе, Россия Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча);

Сабиров Расих Хәсән улы - комиссия рәисе урынбасары, Саба муниципаль районы ветераннар Советы рәисе (килешү буенча);

Галәметдинова Әлфия Ризван кызы - комиссия сәркәтибе, "Саида" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры урынбасары (килешү буенча);

Ибраһимов Илдар Рафил улы - комиссия әгъзасы, Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү Идарәсенең баш киңәшчесе (килешү буенча);

Миргалимов Хафиз Гаяз улы - комиссия әгъзасы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт төзелеше һәм җирле үзидарә комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча);

Фәйзрахманов Хаҗи Ибраһим улы - комиссия әгъзасы, «Саба урманнары» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча).

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Саба муниципаль районы башлыгы урынбасары Р.Р. Закирҗановка йөкләргә.

8. Әлеге карарны «Саба таңнары» район газетасында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы башлыгы                                        Р.Н.Минниханов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль район Советының
2018 елның 09 гыйварындагы
192 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурсны үткәрү тәртибе**

1. "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"гы 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль Хезмәт кодексы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе һәм шартлары билгеләнә (алга таба текст буенча – Башкарма комитет җитәкчесе).
2. Конкурсның төп максаты-муниципаль берәмлекнең башкарма-боеру органы белән нәтиҗәле идарә итүне тәэмин итү өчен Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатуралар билгеләү.
3. Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатураларны карау өчен Конкурс комиссиясе төзелә. Конкурс комиссиясе формалаштырганда конкурс комиссиясе әгъзаларының яртысы Саба муниципаль районы Советы, ә икенче яртысы - Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан билгеләнә.
4. Комиссиянең эш тәртибе әлеге документ белән билгеләнә.
5. Конкурс комиссиясе алты кешедән тора.
6. Конкурс комиссиясе рәисе, рәис урынбасары һәм секретаре комиссия әгъзалары арасыннан Саба муниципаль районы Советы тарафыннан раслана.
7. Конкурс конкурс шартлары, аны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны, контракт проекты басылып чыккан көннән соң 20 көннән дә иртәрәк үткәрелми.
8. Конкурс кандидатның Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасына түбәндәгеләр булу шарты белән үткәрелә:

а) Россия Федерациясе гражданлыгы;

б) югары һөнәри белеме;

в) муниципаль хезмәт стажы кимендә ике ел яки белгечлек, юнәлеш буенча кимендә биш ел эш стажы;

г) җитәкче, оешма җитәкчесе урынбасары, дәүләт органы, җирле үзидарә органы вазыйфаларында, шулай ук аларның структур бүлекчәләре җитәкчеләре вазыйфаларында биш елдан да ким булмаган идарә эшчәнлеге тәҗрибәсе.

д) Башкарма комитет җитәкчесенең вазыйфаи бурычларын үтәү өчен кирәкле күләмдә түбәндәге һөнәри белемгә һәм күнекмәләргә:

– вазыйфаи бурычларны үтәүгә карата Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары, Татарстан Республикасы Конституциясе; Татарстан Республикасы Президенты указлары, Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары, хезмәт законнары; салым законнары, Саба муниципаль районы муниципаль берәмлеге уставлары, башка норматив хокукый актлар, муниципаль хезмәт үтүнең хокукый нигезләре, идарә итү, хезмәт күрсәтүне оештыру нигезләре һ. б. белергә

тиеш; хезмәт бурычларын үтәүгә карата үзебезнең һәм чит ил тәҗрибәсе, массакүләм мәгълүмат чаралары, гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү формалары һәм методлары; эшлекле этикет кагыйдәләре; хезмәтне саклау кагыйдәләре һәм нормалары, куркынычсызлык техникасы һәм янгынга каршы яклау кагыйдәләре; хезмәт регламенты, хезмәт мәгълүматы белән эшләү тәртибе; вазыйфаи инструкциясе;

– һөнәри күнекмәләргә ия булырга: структур бүлекчәләр Җитәкчелеге, идарә итү һәм башка карарларны оператив кабул итү һәм гамәлгә ашыру; карарлар эшләү һәм кабул итү, үз гамәлләре нәтиҗәләрен фаразлау процессында аналитик бәяләү; кадрлар сайлау һәм урнаштыру, персонал белән идарә итү; эшлекле сөйләшүләр алып бару, гавами чыгышлар алып бару, эшлекле хат төзү; вазыйфаи бурычлардан чыгып эшне планлаштыру;

- мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендә хокукый аспектлар, программ документлар һәм мәгълүмати-коммуникацион технологияләр өлкәсендә дәүләт сәясәтенең өстенлекләре, мәгълүмат-коммуникация технологияләрен куллану юлы белән халыкка һәм оешмаларга дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хокукый аспектлар, аппарат һәм программа тәэминаты, муниципаль органнарда заманча мәгълүмати-коммуникацион технологияләр куллану мөмкинлекләре һәм үзенчәлекләре, шул исәптән ведомствоара документлар әйләнеше мөмкинлекләреннән файдалануны да кертеп, муниципаль органнарда заманча мәгълүмати-коммуникацион технологияләр куллану мөмкинлекләре һәм үзенчәлекләре, мәгълүмати куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендә гомуми мәсьәләләр, проект белән идарә итү нигезләре турында белергә тиеш;

– муниципаль органнарда заманча мәгълүмат-коммуникация технологияләрен куллану мөмкинлекләрен һәм үзенчәлекләрен исәпкә алып, стратегик планлаштыру һәм төркем эшчәнлеге белән идарә итү, компьютерның эчке һәм периферийлы җайланмалары белән эшләү, мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләре белән эшләү, шул исәптән Интернет челтәре белән эшләү, операцион системада эшләү, электрон почта белән идарә итү, текст редакторында эшләү, электрон таблицалар белән эшләү, мәгълүматлар базалары белән эшләү, проектлар белән идарә итү системалары белән эшләү хөнәри күнекмәләре булырга тиеш;

9. Конкурста катнашырга теләүче затлар конкурс комиссиясенә әлеге Тәртипкә кушымтада күрсәтелгән форма буенча гариза бирәләр, аңа түбәндәге документлар тапшырылырга тиеш:

1) 3 х 4 см зурлыгындагы фотография һәм әлеге тәртипнең №2 кушымтасы нигезендә үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета;

2) автобиография;

3) паспортның яисә шәхесен раслаучы башка документының төп нөсхәсе һәм күчермәсе (тиешле документ документларны тапшырганда һәм конкурска килгәч шәхсән тапшырыла);

4) югары белемне, эш стажын һәм квалификацияне раслаучы документлар:

- гражданинның хезмәт эшчәнлеген раслый торган хезмәт кенәгәсенең яисә башка документларның төп нөсхәсе һәм күчермәсе;

- һөнәри белем турындагы документларның төп нөсхәсе һәм күчермәсе, шулай ук, гражданин теләге буенча, өстәмә һөнәри белем бирү, гыйльми дәрәҗә бирү турында документлар. Конкурсант профессиональ әзерлеген характерлаучы башка документларны да өстәмә рәвештә тәкъдим итә ала.

5) Россия Федерациясе Президентының «Керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында"гы 2014

елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган үзенең, иренең (хатынының), балигъ булмаган балаларының 2017 елга керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә;

6) муниципаль хезмәткә керүгә комачаулаучы авыруның булмавы турында медицина учреждениесе бәяләмәсе;

7) мәҗбүри пенсия иминиятенең иминият таныклыгы, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелә торган очраклардан тыш;

8) физик затның Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында исәпкә кую турында таныклык;

9) хәрби исәпкә алу документлары-хәрби бурычлылар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен;

10) хөкемгә тартылу (булмавы) турында белешмә.

10. Комиссия конкурска тапшырылган документларны өстәмә тикшерү, шулай ук претендентлар турында башка мәгълүмат соратып алу хокукына ия.

11. Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып күрсәтү гражданинга аларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

12. Гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар Саба муниципаль районы Советы аппараты хезмәткәрләре тарафыннан махсус журналда кабул ителә һәм теркәлә.

Гариза тапшырган затка документлар алуда, аларның исемлеген һәм алу датасын күрсәтеп, расписка бирелә.

13. Документларның төп нөсхәләре гариза бирүчегә аларны тәкъдим иткән көнне кире кайтарыла, ә күрсәтелгән документларның күчермәләре делога теркәлә.

14. Конкурс Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның әлеге вазифага квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

15. Конкурска «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында " 25-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясында каралган муниципаль хезмәт белән бәйле чикләүләр булган затлар кертелми.

Конкурста катнашудан баш тарткан очракта гражданин әлеге карарга суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

16. Конкурс комиссиясе кандидатларны үзләре тәкъдим иткән мәгариф, граждан яки башка дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәт узу, башка хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру турындагы документлар нигезендә, шулай ук федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килмәгән кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларын кулланып конкурс процедуралары нигезендә бәяли.

Кандидатларны тикшерү һәм сайлап алу Конкурс комиссиясенең ябык утырышларында гамәлгә ашырыла. Конкурс комиссиясе утырышы конкурс комиссиясе әгъзаларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

17. Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре карар белән рәсмиләштерелә, утырышта катнашкан рәис, рәис урынбасары, комиссия секретаре һәм конкурс комиссиясе әгъзалары кул куя.

18. Конкурс комиссиясе карары кандидат юклыкта кабул ителә.

19. Конкурс комиссиясе карары комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. «Риза» һәм «каршы» тавышлары тигез булган очракта, рәис тавышы хәлиткеч булып тора.

20. Конкурс нәтиҗәләре һәм кандидатлар турында мәгълүмат Саба муниципаль районы Советына конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан тәкъдим ителә.

21. Конкурс комиссиясе Саба муниципаль районы Советына Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасына дәгъва кылучылар арасыннан кимендә ике кандидатура тәкъдим итә.

22. Әгәр конкурсны үткәрү нәтиҗәсендә Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасына квалификация таләпләренә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаса, конкурс комиссиясе тәкъдиме белән Саба муниципаль районы Советы кабат конкурс үткәрү турында карар кабул итә.

Кабат конкурс үткәрү турындагы карар Саба муниципаль районы Советы тарафыннан шулай ук конкурс комиссиясе тәкъдим иткән кандидатларның берсе дә Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасына билгеләнмәгән очракта кабул ителә.

23. Конкурс нәтиҗәләре буенча Башкарма комитет Җитәкчесен билгеләү турындагы карар Саба муниципаль районы Советы тарафыннан Саба муниципаль районы Советының якындагы утырышында кабул ителә.

24.Конкурста катнашуга кертелмәгән Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүгә дәгъва итүчеләрнең һәм конкурста катнашучы кандидатларның документлары Саба муниципаль районы Советы тарафыннан Башкарма комитет Җитәкчесен билгеләү турында карар кабул ителгәннән соң 30 көн эчендә язма гариза буенча кире кайтарылырга мөмкин. Бу срок тәмамланганчы документлар Саба муниципаль районы Советы аппаратында саклана, шуннан соң юкка чыгарылырга тиеш.

25.Конкурста катнашу белән бәйле чыгымнар (конкурс үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак урынын наемга алу, яшәү, элемтә чараларыннан файдалану һәм башкалар) кандидатлар тарафыннан үз акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.